КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 3 апрель г.Казань № 224

Төзелеш тармагында эшләүче беренче разрядлы эшченең уртача айлык хезмәте өчен түләү күләме турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзелеш ресурслары бәяләрен мониторинглау турында» 2016 елның 23 декабрендәге 1452 номерлы карары белән расланган Төзелеш ресурслары бәяләрен мониторинглау кагыйдәләренең 221 нче пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклап калу эшләренең, капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең, капиталь ремонтлауның, җимерүнең смета кыйммәтен билгеләү максатларында төзелеш тармагында эшләүче беренче разрядлы эшченең уртача айлык хезмәте өчен түләү күләмен 2023 елга 34 985,28 сумга тигез итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелеш тармагында мәшгуль булган беренче разрядлы эшче хезмәте өчен түләүнең уртача айлык күләме турында» 2023 ел, 20 апрель, 502 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин